ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**"Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 21 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында" 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 5, № 11 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 1 – 2) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяда:

а) 1 пунктка түбәндәге эчтәлекле "б$^4$" пунктчасын өстәргә:

"б$^4$) депутат үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне тапшырмаганда яисә үз вакытында тапшырмаганда;";

б) 4 пунктта "законнарда каралган" сүзләрен "Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законда һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексында каралган" сүзләренә алмаштырырга;

2) 10$^1$ статьяда:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Депутат ел саен финанс хисабы елыннан соң килә торган елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенә (алга таба әлеге статьяда – Комис-

сия) үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш.";

б) 3 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3) белешмәләр тапшырыла торган елга кадәрге календарь ел дәвамында (алга таба – хисап чоры) үзе тарафыннан, хатыны (ире) һәм (яисә) балигъ булмаган балалары тарафыннан җир кишәрлеген, башка күчемсез мөлкәт объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләрен, пайларын) сатып алуга кагылышлы һәр башкарылган алыш-биреш буенча, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артса, үзенең чыгымнары турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында һәм бу алыш-бирешләр башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр.";

3) $10^4$ статьяның 1 пунктындагы 4 пунктчасында "җир кишәрлеген, башка күчемсез мөлкәт объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләрен, пайларын) сатып алу буенча чыгымнар турында, әгәр алыш-биреш суммасы депутатның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш башкарылганчыга кадәр соңгы өч елда гомуми кеременнән артса, һәм алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары" сүзләрен "чыгымнар" сүзенә алмаштырырга;

4) түбәндәге эчтәлекле $10^5$ статья өстәргә:

"$10^5$ статья. **Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу максатларында депутатларга бирелә торган йөкләмәләр**

Депутат "Коррупциягә каршы көрәш турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарында билгеләнә торган нигезләр булганда һәм тәртиптә, үз вәкаләтләрен башкарганда мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында Комиссиягә хәбәр итәргә, шулай ук мондый конфликтны булдырмау яисә җайга салу буенча чаралар күрергә тиеш.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көннән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2016 елның 21 апреле
№ 23-ТРЗ